## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"28" ноябрь 2020 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 28 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2020 елның 28 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

– Кышлау авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү;

- бензин триммеры сатып алу.

2) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Кышлау авылы территориясен чистарту, Татарстан һәм Чапаев урамнары арасындагы күпер буенда агачлар һәм куаклар кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү, килешү буенча хезмәт хакы түләү;

- урам утларына хезмәт күрсәтү өчен хезмәт хакы түләү;

- тукталыш мәйданчыгын ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы өчен түләү.

3) Кышлау авылы скверын төзекләндерү:

- газон чабу, утырту материалы алу, яктырткычлар сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү.

4) Физик культура һәм спортны үстерү:

- хоккей тартмасын ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 262 (ике йөз алтмыш ике) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 202 (ике йөз ике) кеше, бу 77,09 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 202 (ике йөз ике) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. "Сез 2021 елда Кышлау авыл җирлеге Кышлау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:
– Кышлау авылы зираты территориясен киртәләп алу өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү;
- бензин триммеры сатып алу.
2) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- Кышлау авылы территориясен чистарту, Татарстан һәм Чапаев урамнары арасындагы күпер буенда агачлар һәм куаклар кисү, транспорт хезмәтләре күрсәтү, килешү буенча хезмәт хакы түләү;
- урам утларына хезмәт күрсәтү өчен хезмәт хакы түләү;
- тукталыш мәйданчыгын ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы өчен түләү.
3) Кышлау авылы скверын төзекләндерү:
- газон чабу, утырту материалы алу, яктырткычлар сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү.
4) Физик культура һәм спортны үстерү:
- хоккей тартмасын ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Кышлау авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кышлау авыл җирлеге башлыгы Шакирова Р.Ф.

Совет Кшкловского сельского поселения
Кышлау авыл җирлеге Советы